УКД 76.03.09

*Р.Н. Галиева*

# 1920 ЕЛЛАР ТАТАР ПЛАКАТЛАРЫНЫҢ ВИЗУАЛЬ ТЕЛЕ ҺӘМ ПЛАСТИК ЧИШЕЛЕШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Статья посвящена яркому и своеобразному явлению отечественного искусства – татарскому плакату 1920-х гг., в котором отразились особенности революционной графики и проявилась связь с национальными и региональными видами татарской художественной культуры такими, как настенные календари, шамаили, театральные афиши, получившие активное развитие на рубеже XIX–XX вв. Анализируя их формы и содержание автор показывает, как в них вырабатывались принципы взаимодействия текста и изображения, проявившиеся затем в плакате. В качестве основных отличительных особенностей татарских плакатов 1920-х гг. автор указывает двуязычие и использование в татарском языке до конца 1920-х гг. арабской графики, а также введение национального компонента через татарские типы, костюмы, обычаи, предметы быта. В качестве приоритетных жанров выделяются просветительские, а также рекламные плакаты, активно развивавшиеся со второй половины 1920-х. гг. Рассматривая художественные особенности татарских плакатов, автор выделяет два направления – реалистическое и авангардное, обращаясь к произведениям конкретных художников. Многочисленные реалистические плакаты Г. Арсланова на санитарно-гигиенические темы при несовершенстве художественных форм вносили значимый вклад в просвещение народа. Представители авангардного направления (Ф. Тагиров, Ш. Мухамеджанов и др.) работали преимущественно в рекламном плакате, используя разнообразные методы и приемы. В конструктивистских плакатах Ф. Тагирова модернизированный арабский шрифт, на основе почерка куфи, сочетался с абстрактными или предельно геометризованными формами. Ш. Мухамеджанов, работая с латиницей, оперировал условными фигуративными формами, применял фотомонтаж. Автор приходит к выводу о том, что оба направления в татарском плакате, пропагандируя новые идеи, используя новые художественные методы, сохраняли национально-культурные особенности.

**Ключевые слова:** плакатное искусство, реализм, авангард, шамаиль, календарь, афиша, арабская каллиграфия, яналиф (латиница).

The article is devoted to the bright and peculiar phenomenon of Russian art – the Tatar poster of the 1920s., which reflected the features of revolutionary graphics and showed a connection with national and regional types of Tatar art culture such like wall calendars, shamail, theater posters, which were actively developed at the turn of the XIX–XX centuries. Analyzing their forms and content, the author shows how they developed the principles of interaction between text and image, which then appeared in the poster. As the main distinguishing features of Tatar posters of the 1920s. the author indicates bilingualism and use in the Tatar language until the end of the 1920s. Arabic graphics, as well as the introduction of a national component through Tatar types, costumes, customs, everyday life. Educational and advertising posters, which have been actively developing since the second half of the 1920s, are

highlighted as priority genres. Considering the artistic features of Tatar posters, the author identifies two directions, realistic and avant-garde, referring to the works of specific artists. Numerous realistic posters of G. Arslanov on sanitary and hygienic topics with imperfect art forms made a significant contribution to the education of the people. Representatives of the avant-garde style (F. Tagirov, Sh. Mukhamedzhanov, etc.) worked mainly in an advertising poster, using a variety of methods and techniques. In F. Tagirov's constructivist posters, modernized Arabic script, based on kufi handwriting, was combined with abstract or extremely geometrized forms. Sh. Mukhamedzhanov, working with the Latin alphabet, operated on conditional figurative forms, used photomontage. The author comes to the conclusion that both directions in the Tatar poster, promoting new ideas, using new artistic methods, preserved national and cultural characteristics.

**Keywords:** Poster art, realism, avant-garde, shamail, calendar, poster, Arabic calligraphy, yanalif (Latin).

1920 еллар татар плакаты уникаль төбәк һәм милли үзенчәлекләрнең күпкырлы палитрасын чагылдыра. Аның үзенчәлекләре һәм стилистик чагылышлары Татарстан АССР өчен хас була. Аның барлыкка килүе рус плакатының үсеше белән дә, татар сәнгати мәдәниятенең традицион формалары белән дә тыгыз бәйләнгән. Дини кануннар тарафыннан хайван һәм кеше сурәтләренең тыелуы әлеге формаларның үсешен чикли. Нәтиҗәдә, шартлы сәнгать теле барлыкка килә. Һәм ул гарәп каллиграфиясендә, декоратив-гамәли сәнгатьтә гәүдәләнеш таба. Гарәп каллиграфиясе сәнгате күп гасырлар дәвамында татар мәдәниятенең аерылгысыз өлешен тәшкил итә. Чикләү һәм тыюларга карамастан, чынбарлыктагы дөнья татар сәнгатендә предметларның, үсемлекләрнең һәм гыйбадәт кылу урыннарының символик сурәте рәвешендә яши. Реалистик сурәтләр XX гасыр башында аеруча активлаша, бу – татар җәмгыятен модернизацияләүгә һәм милли мәдәниятне рус һәм Европа мәдәниятенә якынайтырга омтылган җәдитчелек хәрәкәте белән бәйле була. Реалистик сурәтләр татар сәнгати мәдәниятенең календарь һәм шәмаил кебек төрләренә актив кертелә башлый. Соңгылары – татар плакатының турыдан-туры элгәрләре.

XIX гасырның икенче яртысыннан башлап актив үсеш кичергән татар календарьлары еш кына гамәли характерда булып, көндәлек тормышта файдалы күптөрле мәгълүматны үз эченә алган. Календарьлар табигате белән, плакатлар кебек үк, күпжанрлы булганнар, эчтәлек һәм функциональ билгеләнешенә карап, берничә категориягә бүленгәннәр:

– фәнни-сәнәгати;
– әдәби;
– фәнни-әдәби;
– сәүдә белән бәйле;
– гомуми файдалану өчен [2: 44].

Полиграфик эшләнеше һәм формасы ягыннан календарьларның берничә төре була: дивари плакат-календарь; дивари өзмә календарь;

кесә календаре. Татар календаре көннәр, айлар, даталар һәм бәйрәмнәр исемлеген үз эченә алган белешмә басма гына түгел, ә тормышның төрле өлкәләрен чагылдырган кыска мәкаләләрне, белдерү, реклама характерындагы материалларны, легенда һәм кыйссалар, мәкальләр, биографик мәгълүматлар, фотоматериаллар, рәсемнәр, астрономик карта һәм схемаларны сыйдырган мөстәкыйль чыганак та булып тора [2: 120]. XIX гасыр азагында татар мәгърифәтчесе К. Насыйри календарьларына Казан мәчетләренең, Сөембикә манарасының рәсемнәре кертелә. 1883 ел календаренда авторның үзе тарафыннан ясалган астрономик карталар, схемалар урын ала [2: 77]. Казанда Бертуган Кәримовлар типографиясендә өч ел дәвамында (1908–1910) нашир С.И. Строгановның календарьлары чыгарыла, һәр басманың эчтәлеге үзгә: беренчесендә «Ландыш» сабыны рекламалана, моннан тыш, календарьда Мөхәммәд пәйгамбәрнең шәхси гигиенаны үтәүнең мөһимлеген ассызыклаган сүзләре дә бар [2: 50]. Әлеге мисаллар Татарстан плакат сәнгате һәм (эчтәлеге, функциональ бурычлары ягыннан) зур практик әһәмияткә ия, шулай ук бай тематик бизәлешле календарьлар арасында охшашлыкларның аеруча күп булуын ышандырырлык итеп раслый. Календарьларда кайвакыт басма шәмаилләрне дә очратабыз, мөселман бәйрәмнәре дә аларга бәйле күрсәтелә [8: 38].

Татар басма шәмаиле – Коръән сүрәсе яки башка дини эчтәлекле сүзләр гарәп каллиграфиясен кулланып язылган һәм сакраль мәгънәгә ия дивар панносы ул. Шул исәптән төсле литография ысулы белән нәшер ителгән басма шәмаил XIX гасырда Казанда беренче милли типографияләр ачылуга бәйле рәвештә барлыкка килә һәм үсә [8: 21]. 1840 еллар башына шәһәрнең берничә типографиясе шәмаилләр бастырып чыгару белән шөгыльләнә. Берсе – Яңа Татар Бистәсендә, икенчесе шәһәр үзәгендә (Шевицның Шәрык типографиясе) урнаша. Шулай ук XX гасыр башына И.В. Перов, А.М. Кокорев (соңрак В.В. Вараксин), И.Н. Харитонов, Г.М. Вечеслов, М.А. Чиркова, В.З. Еремеев һәм А. Шашабрин, бертуган Мөхәммәтҗан һәм Шәрифҗан Кәримовларның шәхси типографияләрендә дә шәмаилләр чыгарыла [8: 22]. Басма шәмаилләрне профессиональ рәссам-каллиграфлар эшли. Еш кына шәмаилнең композицион чишелешенә гарәп язмасының төрле каллиграфик ысулларда башкарылган язулары һәм милли орнаментлар гына түгел, ә стильләштерелгән сурәтләр дә кертелә: әйтик, Мәккә, Мәдинә, Истанбул (Константинополь), Иерусалим һәм башка шәһәрләрнең архитектура һәйкәлләре һәм мөселманнарның изге урыннары, ислам дине символлары. Кайбер шәмаилләр вак детальләргә бай булып һәм аскы өлештә аңлатма язуы биреп, шәһәр пейзажы принцибы буенча эшләнә. Шәмаил дини табыну объекты гына түгел, ә үзенчәлекле картина булып, өйнең интерьерын да бизәп тора, аның төп сәнгати элементлары – шрифт һәм орнамент. Татар рәссамнары сурәтне метафорик ысуллар ярдәмендә тәкъдим итәләр һәм стильләштерәләр, шәмаилнең стилистик мөмкинлекләрен һәм эчтәлеген киңәйтәләр,

эстетик сыйфатлар өстиләр һәм кайбер реалистик мотивлар кертеп җибәрәләр. С.М. Червонная билгеләп үткәнчә, шәмаилдә стильләштерелгән предметлар гарәп язмасы белән симбиоз бәйләнеш һәм стилистик бердәмлек тәшкил итә. Хәрефләрдә, метаморфозалар узып, төрле архитектура элементлары ачык күренә башлый [7: 266]. Шәмаилләргә осталар каллиграфик ысул белән шулай ук һиҗри ай исемнәрен, мөнәҗәт, бәетләрдән алынган өзекләр һәм башка шигъри юллар, афоризмнар, мәкаль-әйтемнәрне дә язганнар [1: 31]. Татар басма шамаиленең образлы төзелеше һәм пластик чишелеше 1920 еллар татар плакатында чагылыш таба. Шәмаилне үзенә буйсындырган визуаль принциплар, шрифт һәм орнамент композицияләрен урнаштыру методлары татар плакатларының сәнгатьчә чишелешен алдан билгели.

1920 елларда татар плакатының тагын бер үсеш чыганагын татар театры афишасы тәшкил итә. XX гасыр башы татар театрының актив эшчәнлек күрсәтүе соңгысының тиз үсүенә сәбәп була. Татар театры афишасы үзенчәлекле сәнгати якын килү һәм чишелеше белән аерылып тора, шуңа күрә ул реклама һәм афиша арасындагы балансны саклаган плакат сәнгатенең аерым төре итеп карала ала. Афишаларда кулланылган гарәп язмасы үзе үк плакат бизәген хәтерләтә. Бу очракта татар кульязма һәм басма китапларының бизәлеше белән бәйләнеш күзәтелә: китап битләре дә афишалардагы элементлар – бордюр, зигзаг, виньетка һәм ромблар белән бизәлә [3: 16]. Татар театры плакаты литография яки типография наборы техникасында эшләнә. Бу плакатларның күбесе аноним була.

1920 елларда татар плакаты барлыкка килү беренче чиратта җәмгыятьтәге революцион үзгәрешләр һәм Гражданнар сугышы белән бәйле була. Бу чорда плакат, агитация-массачыл сәнгатьнең бер өлеше буларак, күп кенә мәсьәләләрне – агитация, пропаганда, культура-агарту, аеруча кискен проблемаларны ачыклау кебек бурычларны хәл итәргә тиеш була.

Гражданнар сугышы чоры плакаты, нигездә, иллюстрацияләр характерында булып, анда реалистик күренешләр һәм гади чишелеш өстенлек итә, чөнки плакат киң халык массаларына (күбесенчә укый-яза белмәгән кешеләргә) якын һәм аңлаешлы телдә сөйләргә тиеш. Плакат бастыру белән шөгыльләнгән җирле нәшриятлар шактый төрле булып, шул сәбәпле чыгарыла торган плакатлар палитрасы да бик чуар. Казанда плакат бастырып чыгару белән түбәндәге үзәкләр шөгыльләнә: Республика запастагы армия политбүлеге һәм Идел буе хәрби округы сәяси идарәсе (ПУОКР ПРИВО), Главполитпросвет, Казан губернасы матбугат бүлеге, Госиздат (Губпечатьне алмаштырган), Санпросвет һәм Сәламәтлек саклау халык комиссариаты (Наркомздрав), Ачларга ярдәм (Помгол) оешмасының, Мөселман хәрби коллегиясенең махсус басмалары һ. б. [6: 252]. 1920 еллар башында плакат жанрлары арасында сәяси, агитацион һәм героик плакатлар өстенлек итә. Аларда социаль активлыкка чакыру,

эпидемияләргә каршы көрәш һәм гигиенага өндәү, Идел буенда һәм Россиядә наданлык, җимереклек, ачлык белән көрәш, музейларны үстерүдә булышлык күрсәтергә чакыру кебек темалар күтәрелә.

Казан губернасы инкыйлабка кадәр үк Идел-Урал төбәге халыкларының мәгарифен һәм мәдәниятен үстерүдә зур роль уйнаган фәнни, мәдәни һәм нәшрият үзәге була. Аңа соңыннан автономияле республикаларга әйләнгән төбәкләр – Чуваш һәм Мари АССРлар керә. Казан географик яктан үзенә якын булган башка милли төбәкләр: Башкортстан, Удмуртия АССР һ. б. белән тыгыз бәйләнеш тота. 1920 елларда Казан күрше төбәкләр өчен плакатлар чыгару үзәгенә әверелә. Биредә рус һәм татар телләрендә генә түгел, мари һәм чуваш телләрендә дә плакатлар бастырыла.

Плакатлар күптөсле литография һәм аклы-каралы литография техникасында башкарыла, аларга кайвакыт, кулдан буяп, төсләр өстиләр, сирәк кенә плакатлар линогравюра техникасында эшләнә. Россия революцион плакатының бер өлеше буларак, Казан плакаты башкала плакатларының күп кенә үзенчәлекләрен үзләштерә. Әмма шул ук вакытта җирле үзенчәлекләрне дә үстереп һәм ныгытып, индивидуаль сыйфатлар белән баетыла. 1920 еллардагы татар плакатының төп үзенчәлеге – аның икетеллелегендә: плакат текстлары еш кына параллель рәвештә татар һәм рус телләрендә бирелә. Плакатның композицион структурасы кыска лозунг, сурәт, текст һәм график элементларны үз эченә ала, бу аның күзгә ташланучанлыгын һәм тамашачыга тәэсирен көчәйтү максатыннан эшләнә. Төсләргә килгәндә, алар аз һәм тыйнак, минималь күләм белән чикләнә. Плакат композициясенә гадәттә милли персонаж – татар егете яки татар кызы кертелә. «Татар хатыны! Советлар Россиясенең барлык хезмәтчәннәре сафына бас. Рус пролеткаркалары белән кулга-кул тотынышып, син соңгы богауларны өзәрсең!» дигән плакатта индустриаль пейзаж фонында традицион киемнән, озын толымлы татар хатыны рус кызының кулын кыса. Татар плакатларының иң мөһим үзенчәлекләреннән берсе шунда ки, 1920 еллар ахырына кадәр аларда гарәп графикасы кулланыла. Гарәп язуы аңлатма бирүче текст буларак аста яки өстә урнаша, русча текстны кабатлый. Нәсех язуы күбрәк очрый, тәгълик яки куфи – сирәгрәк.

1920 еллар татар плакаты шактый чуар була, анда, бик кызыклы оригиналь эшләр булуга карамастан, күбесенчә лубоктан төшереп алынган рәсемнәрне хәтерләткән примитив плакатлар өстенлек итә. Әлеге профессиональ дәрәҗәдә эшләнмәгән плакатларда татар рәссамнарының үзләре өчен яңа өлкәдә беренче ышанычсыз адымнары һәм график плакат теленең төп принципларын аңламаулары чагыла. О.Л. Улемнова билгеләп үткәнчә, Казан плакат продукциясе массасында лубоктан төшереп алынган рәсемнәр дәрәҗәсендәге үзешчән әсәрләр күп була. Иске мәктәп рәссамнары плакатның үзенчәлекләрен аңламыйлар һәм аны жанр иллюстрацияләре җыелмасына әйләндерәләр [4: 87]. Рәссам Госман Арслановның (1897–1941) 1927 елда

Татарстан Сәламәтлек саклау халык комиссариаты һәм Кызыл Хачның Татарстан өлкә комитеты тарафыннан халыкны агарту максаты белән нәшер ителгән плакатлар сериясе күбесенчә хатын-кызлар аудиториясенә юнәлдерелә, санитария, гигиена нормаларын, яңа туган баланы карау кагыйдәләрен, шулай ук йөклелек һәм бала тапканнан соңгы тернәкләнү чорына бәйле тәкъдимнәрне үз эченә алып, ана һәм бала сәламәтлегенә аңлы рәвештә якын килергә булыша. Плакатлар иллюстрация характерында, детальләргә бай, өлешчә фактуралар да эшкәртелгән, рәссам орнамент бизәкләре, күп кадрлы композицияләр куллана, традицион милли кием кигән татар кешесе образларын сюжетка кертә, текст рус һәм татар телләрендә тәкъдим ителә. С.М. Червонная ассызыклаганча, 1922 елда Пермьнән Казанга килеп, актив эшли башлаган Г.В. Арсланов татар матбугатында алыштыргысыз, бердәнбер рәссам була: ул авырып китсә, татар журналының чираттагы саны чыкмый кала яки тоткарлана. Сәнгать белгече Г.В. Арсланов рәсемнәренең «эстетик камиллектән ерак» торуын дәлилли, әмма рәссамның сәләте һәм эшкә җаваплы мөнәсәбәте, халык мәгарифенә керткән өлеше югары бәяләнә [6: 190].

1920 еллар уртасында бөтенләй яңа милли авангард плакаты барлыкка килә. Ул реклама плакаты формасында аеруча актив үсеш ала. Аның пәйда булуы яшь татар рәссамнары эшчәнлеге белән бәйле. Иң күренекле вәкилләрнең берсе – Фаик Шакирҗан улы Таһиров (1906–1978). Аның күпкырлы эшчәнлеге китап һәм журнал дизайнын, плакатлар ясауны колачлый, типография шрифтларын эшләүгә керткән өлеше дә зур. Рәссам үз иҗатында революция чоры символларының берсенә әверелгән конструктивизм стилен һәм гарәп каллиграфиясенең күпгасырлык традицияләрен берләштерә. Ф. Таһиров еш кына гарәп каллиграфиясенең иң борынгы язу ысулы булган куфины куллана, ул төгәл квадрат формаларга ия булуы, конструктивизмга туры килгән төгәллеге һәм гадилеге белән аерылып тора. Рәссам үз эшләрендә композиция ясаганда еш кына симметрия һәм ассимметриягә мөрәҗәгать итә. Аның хезмәтләрендә геометрик абстракт формалар: полосалар, түгәрәкләр, ромблар бар, кара һәм кызыл төсләр өстенлек итә, кайвакыт реалистик элементлар да күренгәли, ләкин алар һәрвакыт гомумиләштерелгән һәм стильләштерелгән. Мәсәлән, «Сул аягың белән атла» (1927) плакатында татар крестьяны образы чиктән тыш стильләштерелгән, геометрик фигуралар ярдәмендә мөмкин кадәр төгәл итеп эшләнгән, шул ук вакытта үзенчәлекле милли детальләр дә бар: башында яшел түбәтәй, ак чолгаулы чабата кигән. О.Л. Улемнова болай дип билгеләп үтә: «[для Ф. Тагирова] органичным было оперирование абстрактными формами, которые он использовал как средства выражения мировоззренческих и политических категорий» [5: 7].

1927 елда Татарстанда латин шрифтына – Яңалифкә күчәләр. Ф. Таһиров яңа латин шрифтларын булдыруда һәм яңа алфавитны пропагандалаган реклама плакатлары ясауда актив катнаша, «Яңа-

лиф» нәшрияты белән эшли, «Укый беләсеңме?» (1927) дигән агитплакат ясый, анда ул абстракт композиция төзегәндә симметрия алымын куллана, тамашачыга ике шрифтны күреп чагыштыру, уңайлырагын сайлау мөмкинлеге бирә. Шакир Нигъмәт улы Мөхәммәтҗанов (1900–1972) «Татиздатта китап сатып ал. Газета-журналларга язып» (1929) дигән плакат ясый.

Ул композициягә китап һәм журнал тышлыкларын, газета битләрен кертү өчен, фигуративлык белән шартлылыкны берләштереп, авангард фотомонтаж техникасын куллана. Нәтиҗәдә, яңа басмаларга өндәүче татар кешесе фигурасы абрисы янәшәсендә синкопалы ритмик композиция барлыкка килә.

Шул рәвешле, 1920 еллар татар плакаты яңа график тел эзли һәм элгәреге чор татар сәнгати мәдәнияте казанышларына һәм традицияләренә таянып эш итә. Текст һәм сурәт арасында гармонияле бәйләнеш традицияләре – орнаментка нигезләнгән гарәп язуы, архитектура һәм предмет мотивлары – чагылыш тапкан татар басма шәмаилләре сәнгати чишелеш ягыннан 1920 еллар татар плакат сәнгатенә иң якын торганнары. Плакатның шәмаилдән төп аермасы шунда ки, плакатта традицион шәмаилләрдә булмаган кеше сурәтләре бар. Татар плакаты төп ике – реалистик һәм авангард формаларда үскән, дидек. Реалистик плакат татар шәмаилләренең һәм XIX гасыр календарьларының сәнгати стилистик традицияләрен дәвам итә, аларда барлыкка килгән сурәтләү системасын җәмгыятьнең яңа социаль структурасын чагылдырган персонажлар белән тулыландыра. Авангард плакаты, үз заманы конструктивизм идеяләренә, шулай ук авангард эзләнүләргә аваздаш гарәп каллиграфиясенең борынгы традицияләренә таянып, шушы вакыт ихтыяҗлары нигезендә яңа алымны һәм үткәндәге мирасны синтезлый. 1920 еллар ахырыннан авангард плакаты татар язуының яңа формасын – Яңалифне алга җибәргән төп трибуналарның берсе була. Татар плакатының ике формасы да татар тамашачысы белән үзара бәйләнеш урнаштыруга, аңа аңлаешлы телдә яңа сәяси, социаль, гендер, медицина, мәгариф һәм башка актуаль идеяләрне җиткерүгә юнәлдерелгән (Гражданнар сугышы елларында агитация һәм пропаганда плакаты рәвешендә, 1920 еллар уртасыннан реклама плакаты формасында). Әлеге үзара бәйләнеш хәзерге заман шартларында уникаль татар мәдәниятенә хас үзенчәлекләрне һәм традицияләрне саклап калырга ярдәм итте.

**Әдәбият һәм чыганаклар**

1. *Гилемшин Ф.Ф.* Особенности текстового содержания арабографических шамаилей // Грамота. 2017. № 8(74): в 2-х ч. Ч. 2. С. 29–32.

2. *Миннуллина Л.З.* Татарские печатные календари XIX – начала XX вв. Казань: Заман, 2015. 175 с.

3. *Султанова Р.Р.* История татарского театра в плакатном искусстве. Казань, 2017. 352 с.

4. *Улемнова О.Л.* Казанская графика 1920–1930-х годов. Казань: ИЯЛИ, 2018. 336 с.

5. *Улемнова О.Л.* Пионеры конструктивизма: Фаик Тагиров, Александра Коробкова в Казани и Москве // Пионеры конструктивизма: Фаик Тагиров, Александра Коробкова в Казани и Москве. К 100-летию со дня рождения Фаика Тагирова. Каталог выставки. Казань: Заман, 2006. С. 5–9.

6. *Червонная С.М.* Искусство Советской Татарии. М.: Изобразительное искусство, 1978. 296 с. ил.

7. *Червонная С.М.* Искусство Татарии. М.: Искусство, 1987. 352 с.

8. *Шамсутов Р.И.* Слово и образ в татарском шамаиле от прошлого до настоящего. Казань: Татар. кн. изд-во, 2003. 199 с.

***Галиева Рената Наил кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемедәге Тел, әдәбият һәм сәнгать иститутының Сәнгать белеме үзәге аспиранты*

***Галиева Рената Наилевна,***
*аспирант Центра искусствоведения Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан*
*renata1319@yandex.ru*